**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
ЧЕРЕМШАНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

26.01.2024 **Чирмешән авылы** №13

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының «Лашман урта гомуми белем бирү мәктәбе» гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесенә Минсагит Закир улы Шакиров исемен бирү турында

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының «Муниципаль предприятиеләргә, учреждениеләргә (оешмаларга) исем бирү, аларны гражданнар, оешмалар һәм тарихи вакыйгалар истәлеген мәңгеләштерү максатларында үзгәртү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2017 елның 22 маендагы 95 номерлы карарын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы күренекле гражданнар, оешмалар һәм тарихи вакыйгалар истәлеген мәңгеләштерү турында материалларны карау буенча комиссиянең 2024 елның 19 сентябрендәге 1 номерлы беркетмәсен карап чыгып, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы башкарма комитеты **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының «Лашман урта гомуми белем бирү мәктәбе» гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесенә Минсагит Закир улы Шакиров исемен бирергә.

2. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының «Лашман урта гомуми белем бирү мәктәбе» гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесе исемен түбәндәгечә үзгәртергә:

- Учреждениенең тулы рәсми исеме: Муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение «Лашманская средняя общеобразовательная школа имени Минсагита Закировича Шакирова» Черемшанского муниципального района Республики Татарстан.
- Учреждениенең кыскартылган рәсми исеме: «МБОУ Лашманская СОШ им. М.З. Шакирова».
- татар телендә Учреждениянең тулы рәсми исеме: Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының «Минсагит Закир улы Шакиров исемендәге Лашман урта гомуми белем бирү мәктәбе» гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесе.
- татар телендә Учреждениенең кыскартылган рәсми исеме: “М.З.Шакиров исемендәге Лашман урта мәктәбе” ГБМБУ.

3. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының «Минсагит Закир улы Шакиров исемендәге Лашман урта гомуми белем бирү мәктәбе» гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесе уставын яңа редакциядә расларга.

4. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының «Минсагит Закир улы Шакиров исемендәге Лашман урта гомуми белем бирү мәктәбе» гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесе уставын яңа редакциядә дәүләт теркәвенә салым органына җибәрүгә «Лашман урта гомуми белем бирү мәктәбе» ГБМБУ директорына вәкаләт бирергә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе И.М.Җамалетдинов